Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Круглое Поле авылы
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«21» ноябрь 2022 ел № 7

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы «Бәтке» авыл җирлеге уставы нигезендә

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2022 елда яшәү урыны буенча Бәтке авыл җирлеге Круглое Поле авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Круглое Поле авылында зиратка юлны ремонтлау

2. Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Круглое Поле авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Круглое Поле авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Бәтке авыл җирлеге Башлыгы В.А.Валиева